ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон ______________ КАРАР

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының «2015-2023
елларга Татарстан Республикасы Югары
Ослан муниципаль районында
коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә
ашыру» муниципаль программасын
раслау турында»гы 2014 елның 26
ноябреннән 1737 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«2021-2024 елларга Коррупциягә каршы торуның милли планы турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указының 3 пунктындагы б» пунктчасы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2023 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында»гы 2014 елның 26 ноябреннән 1737 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа чаралары исемлегенең 1 бүлеген 1.14, 1.15 пунктлары белән тулыландырырга.

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.14 | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерция һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуы мониторингы үткәрү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесе, коррупциягә каршы тору эшчәнлеген координацияләү | 2015-2024 еллар | коррупция куркыныч булган мәсьәләләрне карау | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | комиссиясе, җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре | | | | | | | | | | | | | |
| 1.15 | «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча да, үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия секретаре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре | 2015-2024 еллар | коррупция куркынычы булган мәсьәләләрне карау | | | | | | | | | | | |

1.2.Программа чаралары исемлегенең 4 бүлеген 4.14. пункты белән тулыландырырга.

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.14 | коррупциягә каршы тору өлкәсендә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә ел саен квалификацияләрен күтәрүне тәэмин | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесе, коррупциягә каршы тору эшчәнлеген координацияләү комиссиясе, | 2015-2024 еллар | коррупция куркынычы булган мәсьәләләрне карау | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | итү өлкәсендә вазыйфаларын башкаруда катнашучы муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр. | җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре | | | | | | | | | | | | | |

2. «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Шакиров

Кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
«__» ____ номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында 2015 – 2024 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру программасы

ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Югары Ослан муниципаль районында 2015-2024 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Коррупциягә каршы торуның милли планы» ( 2008 елның 31 июлендәге Пр-1568 номерлы РФ Президенты раслаган);<br>- «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы (үзгәрешләр белән);<br>«2015-2024 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы |
| Программаны төп эшләүче | Югары Ослан муниципаль районының коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) |
| Программаның максаты: | Югары Ослан муниципаль районында җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый институтлар эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә коррупция дәрәҗәсен киметү, аның барлыкка килү сәбәпләрен районда җирле үзидарә органнарының һәм граждан җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы эшчәнлеген координацияләүнең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән бетерү. |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | - Коррупция китереп чыгара торган сәбәпләрне һәм шартларны киметү, граждан җәмгыятен коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру процессына җәлеп итү;<br>- Коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;<br>- Дәүләт һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2015-2024 еллар |
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп бирелгән программаны финанслау күләме» | Җирле бюджет акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 510 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сумнарда)<br>2015 ел - 80<br>2016 ел - 80<br>2017 ел - 50<br>2018 ел - 50<br>2019 ел - 50<br>2020 ел - 50<br>2021 ел - 50<br>2022 ел - 50<br>2023 ел – 50<br>2024 ел - 50<br>Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып төзәтмәләр кертергә тиеш. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Муниципаль идарә нәтиҗәлелеге үсеше, социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсе, институтларның һәм граждан җәмгыяте структураларының коррупциягә каршы көрәш процессларында активлыкны арттыру, шул исәптән:<br>- җәмгыятьтә һәм дәүләттә тормышны көйләүнең төп институты буларак законның өстенлеге;<br>- гражданнар һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге оешмалары өчен ачыклык һәм һәркем өчен ачык булу, аларның граждан җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту;<br>- гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын арттыру;<br>- районда инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру;<br>- гражданлык җәмгыяте институтларын үстерү һәм ныгыту;<br>- икътисад өлкәсендә конкурентлы механизмнарны гамәлгә ашыру;<br>- коррупциягә каршы экспертиза буенча эшне камилләштерү;<br>-коррупциягә каршы иҗтимагый фикер формалаштыру;<br>- эшмәкәрлек эшчәнлегенең законлылыгын тәэмин итү. |

## КЕРЕШ

Әлеге Программа «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 - 2023 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру «Дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Программа федераль һәм республика дәрәҗәсендә тормышка ашырыла торган коррупциягә каршы көрәш чаралары системасы белән концептуаль бәйләнгән, һәм муниципаль дәрәҗәдә коррупциягә каршы эшне оештыруда программа - максатчан методны куллану өчен шартлар тудыра.

## I. ПРОГРАММА АЛАРНЫ ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ, АЛАРНЫ ЧИШҮ ЮЛЛАРЫ

Соңгы елларда республикада да, районда да коррупциягә каршы тору чараларының активлашуы, республика һәм муниципаль дәрәҗәләрдә нормалар чыгару һәм хокук куллану эшен камилләштерү белән характерлана.

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указларын, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларын, күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм республика законнарындагы яңалыкларны исәпкә алып коррупциягә

каршы көрәш һәм аларны үзгәртү өлкәсендә иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерү эше алып барылды, Югары Ослан муниципаль районы дәрәҗәсендә район Советы карарлары, коррупциягә каршы тору эшендә аерым юнәлешләрне детальләштерүче район Башлыгы карарлары кабул ителде.

Коррупцион хокук бозуларны һәм башка хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы затлар билгеләнде, аларга коррупцион хокук бозуларны кисәтү буенча кайбер функцияләр бирелгән һәм аларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тоталар.

Билгеләнгән вакытта коррупциягә каршы муниципаль программаның үтәлешенә, аны гамәлгә ашыруның арадаш нәтиҗәләренә анализ ясала, коррупциягә каршы тору турындагы законнарда булган бурычларны һәм программа чараларын исәпкә алып, төгәлләштерелә.

Әлеге программага коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру механизмнарын булдыру, коррупциячел факторларга һәм коррупциягә каршы сәясәт чараларын мониторинглауны оештыру, эшмәкәрлек өлкәсендә коррупциягә каршы көрәш буенча комплекслы чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җитәкче органнар эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү буенча чаралар, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр һәм район җитәкчеләре тарафыннан коррупция фактлары турында гражданнарның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен анализлауны күздә тоткан чаралар кертелгән иде.

Югары Ослан муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәт программасын тормышка ашыру максатларында:
- норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнде;
- гражданнарга һәм юридик затларга муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары эшләнде һәм расланды, алар мәгълүмати стендларда һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган;
- ТР Югары Ослан муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Югары Ослан муниципаль районы» рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәләр эшләнде һәм расланды;
- җирле үзидарә органнарында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлегенә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупция фактлары турында мәгълүмат булу - булмауга анализ ясалды.

Әлеге программаны эшләгәндә коррупциягә каршы милли план нигезләмәләре, 2015-2024 елларга коррупциягә каршы сәясәт стратегиясен гамәлгә ашыру буенча республика программасына кертелгән төп чаралар исәпкә алынды.

Югары Ослан муниципаль районында узган елларда коррупциягә каршы сәясәт Программасыннан алынган төп юнәлешләр булды:
- коррупциягә каршы сәясәт стратегиясен гамәлгә ашыру механизмнарын булдыру буенча оештыру чаралары;
- коррупциягә каршы эшчәнлекне законнар һәм башка норматив хокукый тәэмин итү;
- хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза;
- муниципаль органнар эшчәнлегендә һәркем файдалана алырлык һәм үтә күренмәлелек тәэмин итү,
- эшкуарлык өлкәсендә коррупциягә каршы тору;
- коррупция фактларына, коррупциоген факторларга һәм коррупциягә каршы сәясәт чараларына мониторинг оештыру.

Аларны гамәлгә ашыру вакытын озайтуны таләп итүче чараларга түбәндәгеләр керә:

- норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү, өстенлекле милли проектларны гамәлгә ашыру барышында коррупцион рискларны кисәтү чаралары;
- муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турындагы законнарны үтәвен контрольдә тоту, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны үтәү;
- иҗтимагый торак комиссиясе эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру һәм башкалар.

Әлеге чаралар күп тапкыр үтәлүгә исәпләнгән һәм башкарма хакимият органнары тарафыннан даими игътибар таләп итә.

Халыкны коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру эшенә җәлеп итү максатыннан эшче төркем составына иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре кертелгән.

Коррупциягә каршы көрәштә массакүләм мәгълүмат чараларына мөһим роль бирелә. «Волжская новь» район газетасында даими рәвештә коррупция турында материаллар басылып тора, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы сайтында коррупциягә каршы сәясәткә багышланган бүлек булдырылды, анда коррупциягә каршы комиссия эшчәнлеге яктыртылды.

Район сайтында "Кайнар линия" булдырылган, анда гражданнар коррупция фактлары турында хәбәр итә ала.

Коррупциягә каршы программа нигезләмәләрен үстерүче төп юнәлешләр булып тора:
- коррупциягә каршы тору механизмының нәтиҗәлелеген арттыру буенча оештыру - хокукый характердагы чаралар;
- коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив хокукый тәэмин итү; хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау; коррупциягә каршы тәрбия бирүне оештыру;
- муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы белем бирү системасын формалаштыру;
- коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру чаралары, коррупциоген факторлар мониторингын оештыру һәм үткәрү.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ АНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ТӨП ЭШ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Программаның максаты - коррупция дәрәҗәсен киметү, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм граждан җәмгыяте институтларында коррупциягә каршы эшчәнлекне координацияләүнең нәтиҗәлелеген күтәрү юлы белән җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә аның барлыкка килү сәбәпләрен бетерү.

Программаның бурычлары:
- коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;
- коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;
- дәүләт һәм муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру.
- муниципаль органнар эшчәнлегендә һәркем файдалана алырлык һәм үтә күренмәле булуны арттыру;
- эшкуарлык өлкәсендә коррупциягә каршы тору.

Билгеләнгән бурычларны хәл итү максатларында түбәндәге гамәлләр юнәлешләрен гамәлгә ашыру күздә тотыла:

1. Коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.
2. Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны камилләштерү.
3. Коррупциягә каршы мониторинг системасын гамәлгә кертү.
4. Муниципаль хезмәткәрләрнең, аларның ирлщре-хатыннары һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү ел саен үткәрелә.
5. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия эшчәнлеген активлаштыру.
6. Коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында муниципаль хезмәткәрләргә мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү механизмын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.
7. Коррупциягә каршы комиссия утырышында аның нәтиҗәләрен карап тикшереп, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрендә булган коррупцион күренешләр турында мәгълүмат мониторингын алып бару.
8. Муниципаль заказларны урнаштыру буенча эшчәнлекне оештыруны камилләштерү.
9. Коррупциягә каршы тору өлкәсендә халыкка хокукый белем бирүдә массакүләм мәгълүмат чараларының ролен көчәйтү.
10. Муниципаль органнар эшчәнлегендә һәркем файдалана алырлык һәм үтә күренмәлелек тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру.
11. Эшкуарлык өлкәсендә коррупциягә каршы тору.

III. Программа чаралары исемлеге

| № п/п | Чараның исеме | Җаваплылар<br><br>Башкаручылар | Үтәү вакыты | Көтелгән нәтиҗә | Финансла у чыганагы | Чыгымнар суммасы еллар буенча, мең сум | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | | | | | | | | | | |
| 1. Коррупциягә каршы эшчәнлекне норматив-хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Федераль һәм республика законнарын үтәү йөзеннән, коррупциягә каршы тору турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү. Законнардагы мөмкин булган үзгәрешләрне исәпкә алып, программага үз вакытында төзәтмәләр кертү | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015-2024 еллар | коррупциягә каршы тору өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | |
| 1.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү. Кадрлар | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан | 2015-2024 еллар | муниципаль хезмәт турындагы законнарны үтәү, гражданнарның муниципаль хезмәт өчен тигез | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә ачыклык системасын тәэмин итү һәм массакүләм мәгълүмат чаралары мөмкинлекләреннән файдалану | муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе | | дәрәҗәдә үтәвен тәэмин итү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачык һәм һәркем файдалана алуны тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| 1.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү эшен оештыру һәм үткәрү, шул исәптән коррупциягә каршы эшчәнлек юнәлешләре буенча | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе | 2015-2024 еллар | муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү | Җирле бюджет | 50 | 50 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.4. | Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларының | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма | 2015-2024 еллар | коррупциягә каршы тору эшендә шәхси җаваплылыкны, оешканлыкны һәм һөнәри осталыкны арттыру | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нәтиҗәле эшләвен Югары Ослан муниципаль районының муниципаль хокукый актлары белән йөкләнгән функцияләр нигезендә тәэмин итү | комитетының эшләр идарәчесе | | | | | | | | | | | | |
| 1.5. | Муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы тору турындагы законнар таләпләрен үтәү, муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 2015-2024 еллар | муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирүенә ирешү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү | | | | | | | | | | | | | |
| 1.6. | Муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын үтәүне тәэмин итү | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 2015-2024 еллар | муниципаль хезмәткәрләрнең үз-үзен тотышына һәм коррупциягә каршы билгеләнгән стандартны үтәүгә ирешү | | | | | | | | | | |
| 1.7. | Законда каралган тәртиптә муниципаль хезмәткәрдә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә килә торган мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки барлыкка килү мөмкинлеге турында мәгълүматны тикшерү | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 2015-2024 еллар | муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау | | | | | | | | | | |
| 1.8. | Яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнгән | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты | 2015-2024 еллар | коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәртиптә муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында мәгълүматларны тикшерү | җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | | муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләре конфликты барлыкка килгәндә хәлнең ачыклыгына ирешү | | | | | | | | | | |
| 1.9. | Коррупциягә каршы тору комиссиясенең нәтиҗәле эшләвен, шул исәптән алар эшчәнлегенә граждан җәмгыяте институтлары вәкилләрен җәлеп итү юлы белән дә тәэмин итү | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015-2024 еллар | коррупциягә каршы нәтиҗәле эшчәнлек өчен шартлар тудыру, җәмәгатьчелекнең киң даирәсен җәлеп итү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.10. | Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазифаларны биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тәэмин итү, комиссия составына муниципаль хезмәт белән бәйле фәнни оешмалар һәм белем бирү учреждениеләре вәкилләрен, шулай ук Иҗтимагый совет вәкилләрен һәм башка иҗтимагый вәкилләрне кертү | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 2015-2024 еллар | яллаучы вәкилләренә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе, чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр - конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәүне тәэмин итүдә ярдәм итү | | | | | | | | | | |
| 1.11. | Мәгариф учреждениеләренд | Башкарма комитет | 2015-2024 | мәгариф өлкәсендә | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ә коррупцион куркынычлылык кимүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру | җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары, «Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | еллар | коррупцион күренешләр барлыкка килү куркынычы зонасын киметү | | | | | | | | | | |
| 1.12. | Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре бирү вакытында җир законнарының үтәлешен тәэмин итү | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, «Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (килешү буенча) | 2015-2024 еллар | җирдән файдалану өлкәсендә коррупцион рискларны киметү | | | | | | | | | | |
| 1.13. | Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче | 2015-2024 еллар | муниципаль - хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе эшчәнлегендә ачыклыкка ирешү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | конфликтын җайга салу буенча комиссия эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1.14. | Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, законнарда билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә, мәгълүмат урнаштыру, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерция һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә | Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесе, коррупциягә каршы тору эшчәнлеген координацияләү комиссиясе, җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре | 2015-2024 еллар | җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә ачыклыкны һәм үтемлелекне тәэмин итү, муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәренә һәм мөлкәтенә җәмәгать контроле өчен шартлар тудыру, коррупция куркынычы булган мәсьәләләрне карау | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | катнашуы мониторингы үткәрү | | | | | | | | | | | | | |
| 1.15. | Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына актуаль халәттә ярдәм итү («Коррупциягә каршы тору» бүлеге), мәгълүматны үз вакытында яңарту, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясында каралган чараларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларның мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча да, үтәүне | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия секретаре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре | 2015-2024 еллар | коррупциягә каршы тору буенча күреләә торган чаралар турында гражданнарга мәгълүмат бирү, коррупция куркынычы булган мәсьәләләрне карау | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1.16. | 9 декабрьдә Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү («Түгәрәк өстәлләр», брифинглар, матбугат конференцияләре, хокук саклау органнары белән очрашулар һ. б.) | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары, коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе, ММЧ (килештерү буенча), хокук саклау органнары (килешү буенча) | ел саен | коррупциянең торышы һәм аны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруның барышы турында халыкка мәгълүмат җиткерүне арттыру | Җирле бюджет | 10 | 10 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.17. | 2015-2023 елларга Коррупциягә каршы комплекслы республика программасын үтәүнең барышы турында мәгълүматны Югары Ослан муниципаль районында ТР Юстиция | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | квартал саен | «2015-2021 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» ТР Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | министрлыгына вакытында тапшыру | | | июлендәге 512 номерлы карарын үтәү | | | | | | | | | | |
| 1.18. | Югары Ослан муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында еллык хисапларны Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә үз вакытында бирү | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | ел саен (1 февральгә кадәр) | «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы ТР Законының 14 статьясын үтәү | | | | | | | | | | |
| 1.19. | Җәмәгать берләшмәләре, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Иҗтимагый совет һәм гражданлык җәмгыяте институтлары катнашында коррупциягә каршы тору | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе, Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт (вазифа) | 2016-2024 еллар | муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең коррупцион хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәтен формалаштыру | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын эшләү, шул исәптән бүләкләр алу, бүтән түләүле эш башкару, коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгатьләр турында хәбәр итү бурычлары | тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы каршындагы Иҗтимагый Совет. | | | | | | | | | | | |
| 1.20. | Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәмәгән очракта законнарда каралган юридик җаваплылык чараларын | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе, Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт | 2016-2024 еллар | коррупцион хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | куллануны контрольдә тотуны тәэмин итәргә | урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия | | | | | | | | | | | | |
| 1.21. | Муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы закон таләпләрен үтәүне тәэмин итү | муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия | 2016-2024 еллар | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәмәү очракларын ачыклау буенча эш алып бару. Күрсәтелгән таләпләрне үтәмәүнең һәр очрагына ачыклык бирергә һәм әлеге таләпләрне бозган затларга законнарда каралган юридик | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | җаваплылык чараларын кулланырга | | | | | | | | | | |
| 1.22. | Коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссияләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрергә | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2016-2024 еллар | коррупциягә каршы тору буенча нәтиҗәлерәк эшләү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | |
| 1.23. | Муниципаль хезмәткәрләрдә коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру буенча эшне дәвам итәргә | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2016-2024 еллар | коррупциягә каршы тәрбия бирүне тәэмин итү | | | | | | | | | | |
| 1.24. | Коррупцион күренешләрне киметү һәм су һәм урман законнарын бозуларны кисәтү өчен, урманнарны һәм су саклау зоналарын законсыз куллану һәм төзү белән бәйле хокук бозуларны ачыклау | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика буенча урынбасары, Татарстан | 2016-2024 еллар | коррупцион күренешләр барлыкка килү куркынычы зонасын киметү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | максатыннан, халыкны җәлеп итү максатыннан, «Халык инвентаризациясе » акциясен үткәрергә. Ачыкланган бозуларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрергә. | Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Югары Ослан районы буенча Үзәк территориаль идарәсе инспекциясе әйдәүче белгече (килештерү буенча) | | | | | | | | | | | | |
| 2. Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. | Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен билгеләүче норматив хокукый актлар системасын камилләштерү | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат | 2015-2024 еллар | муниципаль норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы мәҗбүри экспертиза уздыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | | | | | | | | |
| 2.2. | Югары Ослан муниципаль районы җирле | Коррупциягә каршы экспертиза | 2015-2024 | норматив хокукый актларга һәм аларның | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертизаны нәтиҗәле үткәрүне тәэмин итү. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү системасын камилләштерү | үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат | еллар | проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү эшен - оештыруны камилләштерү | | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | ТР Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре турында квартал саен мәгълүмат тапшыру | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат | квартал саен | | | | | | | | | | | |
| 2.3. | Норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы затларның квалификациясен | Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе | 2015-2024 еллар | норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затларның һөнәри | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күтәрү | | | осталыгын арттыру | | | | | | | | | | |
| 3. Коррупциягә каршы мониторинг | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Коррупция торышын мониторинглау максаты белән халык арасында сораштырулар (анкеталаштыру) оештыру һәм үткәрү. Сораштыру нәтиҗәләре турында гражданнарга мәгълүмат бирү | коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015-2024 еллар | җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү | | | | | | | | | | |
